КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 20 гыйнвар г.Казань № 22

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурс үткәрү турында» 2014 ел, 7 март, 146 нчы карары белән расланган энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурс үткәрү буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурс үткәрү турында» 2014 ел, 7 март, 146 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 20 июнь, 421 нче; 2015 ел, 15 сентябрь, 678 нче; 2016 ел, 18 февраль, 102 нче; 2017 ел, 5 июнь, 337 нче; 2017 ел, 27 декабрь, 1040 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурс үткәрү буенча комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

коллегия составыннан М.З.Шакировны чыгарырга;

коллегия составына «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе Әгъзам Самат улы Гобәйдуллинны (килешү буенча) кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин